

**Кече яшьтәге мәктәп балаларын милли – мәдәни чараларга тарту.**

(*Мамадыш шәһәре 2нче номерлы лицееның башлангыч сыйныф укытучысы Сибгатуллина Резида Миргазизовнаның эш тәҗрибәсеннән*)

**“Тормышта без бер тапкыр – нәкъ менә балачак һәм үсмерчакта сәнгать өлкәсендә иҗат итүчеләр булабыз...”**

**П. Блонский.**

Нәкъ менә балалык елларында яшь үзенчәлекләре белән бәйле иҗат чаткылары күренә дә инде. Әмма алар тиешенчә файдаланылмый һәм еш кына вакыт үтү белән юкка чыга. Аңлашыла ки, аларны ныгыту, баету һәм тиешле юнәлеш бирү өчен, үз вакытында һәм максатка ярашлы тәрбияви этәргеч кирәк.

Кече яшьтәге мәктәп балаларын үз вакытында сәнгать дөньясына алып керү аларның башка өлкәләрдә дә иҗат активлыгын үстерергә булышу – безнең төп бурыч. Балада махсус сәләтләрне үстерү аның шәхесенең күпьяклы үсешенә дә ярдәм итә.



Игътибар белән күзәтсәк, уйнаган чакта бала әле актер, әле музыкант була. Тик, кызганычка каршы, мондый чор озакка бармый, кирәксез нәрсә төсле читкә тибәрелә, вакытында үстерелми. Барлык укучыларны да милли – мәдәни чараларга тарту зарур.

Төп максат шунда: һәр кеше, киләчәктә нинди генә һөнәр белән шөгыльләнергә уйламасын, ул тормышны, табигатьне, башка кешеләрне, үз халкының тарихын, мәдәният хәзинәләрен чын зур художникларча бәяли белергә тиеш. Әнә шундый тәҗрибәгә ия булмый торып, балаларга гармонияле, һәр яктан үскән кеше булып өлгерүе кыен. Шундый чаралар кирәклеген без укучылар белән төрле-төрле кичәләр үткәргәндә тоям.

Балачак бәйрәмнәр белән күңелле. Шуңа күрә дә мин татар халкының гореф – гадәтләренә кагылышлы йолаларын чагылдырган бәйрәмнәрен үткәрәм.



Бу укучыларда милли сәнгатькә кызыксыну уятырга, ялын күңелле, нәтиҗәле итеп оештырырга ярдәм итә.  Туган илен яраткан шәхес кенә чын кеше булып формалаша. Ә туган илне ярату туган телне яратудан башлана. Шуңа күрә, укытучының беренче максаты булып туган телгә мәхәббәт уятуы тора. Ә моны эшләү җиңел түгел.  Кече яшьтәге мәктәп балаларын татар халкының күркәм гореф – гадәтләрен чагылдырган бәйрәмнәр үткәрү, аларны үткәргәндә эти - әниләрне катнаштыру, безнең мәктәпнең, татар сыйныфларында матур бер традициягә әйләнде.

2011 – 2012 нчы уку елында да милли бәйрәмнәр күп булды. 4 нче А сыйныфы укучылары көче



белән үткәрелгән “Уңыш бәйрәме” бик матур узды. Бәйрәмгә укучылар үз бакчаларында үстергән уңышлардан күргәзмә оештырдылар. Бу кичәгә мәктәп җитәкчеләре, әти - әниләр, башка сыйныф укучылары кунак итеп чакырылган иде. Бәйрәм шигырьләр, җырлар, сәхнәләштерелгән әсәрләр белән үрелеп барды.

Милли бәйрәмнәрнең берсе булган “Каз өмәсе” күренешен оештырдык. Билгеле инде бу бәйрәмдә әти - әниләр дә читтә калмады. Бәйрәм һәркемгә дә ошады. “Яңа ел” бәйрәме дә җанлы үтте. Һәр сыйныф татар халык әкиятеннән өзек сәхнәләштерде. Укучыларга әкият геройлары булу бик ошады. Бу эшне без яңадан Тукай көнендә дә кабатладык. Аның шигырьләрен, әкиятләрен сәхнәләштерү балаларны тагы да җанландырды.



Якташ шагыйрьләребез, язучыларыбыз белән укучыларны таныштыру безнең мәктәпнең матур бер гадәтенә әйләнде. Балалар мондый чараларга бик теләп катнашалар. Чын шагыйрьне, язучыны күрү аларда китап укырга кызыксыну уята. Мондый очрашуны якташ язучыбыз В.Галеев белән 4 нче А сыйныф укучылары оештырды. Укучылар язучының тормыш юлы, аның иҗат чишмәсе белән якыннан таныштылар. Бу очрашу һәркемдә тирән эзләр калдырды.



Бик күркәм бәйрәмнәрнең берсе булган “Салават күпере” кичәсенә һәр укучы үз өлешен кертте. Балалар һәм укытучылар милли киемнәрдән иде. Бәйрәм татар халкының җырлы – биюле уеннары белән үрелеп барды. Бәйрәмгә кунаклар бик күп чакырылган иде. Алар укучыларның сәләтләренә югары бәя бирделәр.

Мин милли бәйрәмнәр аша, яшь сабый күңелендә күркәм гореф – гадәтләрне саклау һәм яшь буынга тапшыруны максат итеп куябыз.

Һәр чорда һәм җәмгыятьтә талант һәм сәләт югары бәяләнгән, кешеләргә бәхет китергән. Эстетик яктан үскән кеше дөньядагы бер генә нәрсәгә дә ят итеп, җансыз объектка караган кебек кенә карый алмый һәм теләми дә.

Милли кыйммәтләрне тану, үтәү, үстерү, гомумән, яшәү рәвеше дип кабул итү – безнең, укытучыларның, тарихи бурычы. Һәр кеше кече яшьтән үк милли кыйммәтләр йогынтысында тәрбияләнсә генә, үз милләтенең лаеклы шәхесе, зыялысы һәм горурлыгы була ала.